РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

02.12.2019 | № 1629-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлар реестрларын алып бару тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2015 елның 13 июлендәге №220-ФЗ Федераль закон һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында “Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге №107-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлар реестрларын алып бару тәртибен расларга.

2. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең “Саба муниципаль районы территориясендә даими муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудa булган автомобиль транспортында пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлар реестрын һәм гомуми файдаланудa булган автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы пассажирлар йөртүчеләрнең реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында” 2009 елның 16 июнендәге 469-п номерлы карарының 1 пунктындагы 2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлар реестрларын алып бару тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр.

**1.1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутлар реестрларын алып бару тәртибе, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2015 елның 13 июлендәге №220-ФЗ Федераль закон һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында “Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге №107-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутлар реестрын алып бару тәртибе буенча төп нигезләмәләрне (алга таба-Реестр) билгели.

**1.2.** Реестр бердәм мәгълүмат базасыннан гыйбарәт һәм автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары турындагы мәгълүматларны (алга таба – муниципаль маршрутлар) кәгазь һәм электрон рәвештә кертү, үзгәртү һәм архивлауны үз эченә ала.

**1.3.** Гамәлдәге барлык муниципаль маршрутлар реестрга кертелергә һәм исәпкә алынырга тиеш.

### 2. Реестрны формалаштыру һәм алып бару тәртибе.

**2.1.** Реестрны алып бару Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – пассажирлар йөртүне оештыручы) тарафыннан кәгазь һәм электрон рәвештә, әлеге Тәртипнең 1 кушымтасында билгеләнгән форма буенча тәэмин

ителә. Кәгазь һәм электрон чыганаклардагы язмалар туры килмәгән очракта, өстенлек кәгазьдәге язмага бирелә **.**

**2.2.** Маршрутлар реестры Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органы (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан алып барыла.

**2.3.** Реестрны алып бару бердәм мәгълүмат базасына муниципаль хәбәр маршрутлары турында түбәндәге язмаларны кертү юлы белән башкарыла (алга таба-язмалар):

1) Саба муниципаль районының гамәлдәге, шулай ук яңа ачылган муниципаль маршрутларын теркәү турында язмалар;

2) Саба муниципаль районында муниципаль маршрутларны үзгәртү турында язмалар;

3) Саба муниципаль районында муниципаль маршрутларны ябу турында язмалар.

**2.4.** Гамәлдәге, шулай ук яңа ачылган муниципаль маршрутка, әлеге маршрут турында язу реестрына беренче тапкыр керткәндә, тәртип теркәү номеры бирелә. Тәртип теркәү номерлары гамәлдәге, шулай ук Саба муниципаль районында яңа ачылган муниципаль маршрутлар турындагы язмалар реестрына кертелгән саен өзлексез бирелә. Реестр буенча тәртип теркәү номеры бер генә тапкыр кулланылырга мөмкин.

**2.5**. Муниципаль маршрутларны ачу, үзгәртү һәм ябу вакытында реестрга язулар кертү өчен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары һәм маршрутның расланган паспорты булу нигез булып тора.

**2.6.** Реестрга кертелә торган язмаларда Саба муниципаль районындагы муниципаль маршрутлар турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының тиешле Реестрда теркәү номеры;

2) даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының аңа әлеге маршрутны билгеләгән җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән тәртип номеры**;**

3) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исемнәре рәвешендә яки әлеге маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләрнең исемнәре рәвешендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының атамасы;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча арадаш тукталыш пунктлары исемнәре яки чикләрендә арадаш тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләр исемнәре;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнарның, автомобиль юлларының исемнәре;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының озынлыгы;

7) пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе (бары тик тукталыш пунктларында яисә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган урында гына);

8) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төре;

9) дәүләт яисә муниципаль контракт, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелә торган ачык конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән ачык конкурста катнашуга (яисә) заявка, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү яисә үзгәртү турында карар белән каралган транспорт чараларына характеристикалар;

10) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча файдалану рөхсәт ителә торган транспорт чараларының һәр классының максималь саны;

11) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруны башлау датасы;

12) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы салым түләүченең исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (индивидуаль эшкуар өчен), идентификация номеры;

13) башка белешмәләр.

**2.7.** Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр (индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш) Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

## 3. Реестрга кертү һәм реестрдан төшереп калдыру тәртибе

**3.1.** Реестрга маршрутны кертү һәм төшереп калдыру, реестрга үзгәрешләр кертү Саба муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль маршрутны билгеләү, үзгәртү яисә бетерү турындагы карары кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

**3.2.** Кәгазь чыганакта алып барыла торган реестрга үзгәрешләр өстәмә язу кертү юлы белән башкарыла. Үзгәрешләр, фамилиясе, инициаллары күрсәтелеп, вәкаләтле белгечнең имзасы белән таныклана.

**3.3.** Электрон рәвештә алып барыла торган Реестрга үзгәрешләр турыдан-туры реестрның башлангыч текстына үзгәрешләр кертү юлы белән башкарыла. "Башка мәгълүмат" графасында кәгазь чыганактагы реестрга язмалар керткән белгечнең фамилиясе һәм инициаллары күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
территориясендә автомобиль транспортында даими
рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның
муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару
тәртибенә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрлары**

| Тиешле Реестрда регуляр пассажирлар йөртү маршрутының теркәү номеры | Даими пассажирлар йөртү маршрутының тәртип номеры | Даими пассажирлар йөртү маршрутының исеме | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча арадаш тукталыш пунктларының исемнәре яки чикләрендә арадаш тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләр исемнәре | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнар, автомобиль юллары исемнәре | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының озынлыгы, км | Пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе | Даими рәвештә пассажирлар йөртү төре | Транспорт чаралары характеристикалары төрләре һәм класслары, транспорт чараларыннан максималь файдалану вакыты, транспорт чараларының экологик характеристикалары | | | | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча файдалану рөхсәт ителә торган һәр класслы транспорт чараларының максималь саны | Даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлау датасы | Шартнамә номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы салым түләүченең исеме, тору урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (шәхси эшкуар өчен), идентификация номеры | Башка белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Төр | Класс | Транспорт чараларын | Транспорт чаралары | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | нан максималь файдалану срогы | ның экологик характеристикалары | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9а | 9б | 9в | 9г | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | |

Реестрны алып бару өчен җаваплы: ____________________ ________________________________ ______________________________

(имза) (вазыйфа) (Ф.И.АИ.)

Саба муниципаль районы

Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов